# Фәрештәләр сезгә юлдаш булсын, Хәерле юл телим, туганнарым!..



Хәмит ЛАТЫЙФ

## Хәерле юл телим

Күпме гомер яшәлде лә җирдә,
Аһ, аяусыз язмыш бураннары!
Яралары килеп өшеткәндә,
Җылы кебек иде узганнары.

Аяусыз ла булды ул бураннар,
Килеп кайчак тынсыз калдырдылар;
Адаштырып мине бу кырларда,
Әллә инде юлдан яздырдылар.

Гомер үтте, кемнәр юлга чыгар,
Җиңә-җиңә язмыш бураннарын?
Фәрештәләр сезгә юлдаш булсын,
Хәерле юл телим, туганнарым!

## Үги ана

*Биш яшькә кадәр карап үстергән*
*үги әнием Дөхедия Ахуновага*

Ап-ак кардай чәчләреңне
Дала җиле тарый микән?
Үги ана - изге ана, дип,
Балаларың таный микән?

Синең улың булмасам да,
Улым, диеп кала идең;
Шул баланы ташлама, дип,
Ходаеңа бага идең.

Җил-давылда гаҗиз калсам,
Хәлем бетеп җиргә аусам,
Тузан булып очты барсы җилгә,
Яңа туган көнне башламастан.

## Яра

Соңгы сулышында уйлагандыр
Үксез кала, диеп, балаларым.
Инде ничә еллар җанда сызлый
Әтиемнең сугыш яралары.

## Җир һәм күк

Уйлар күктә оча талгын гына,
Ә мин җирдән - адәм баласы.
Уйлар кебек җан очса да күккә,
Ә тәнем бит җирдә каласы.

## Яфраклар түшәлгән юлларда

Кагылган-сугылган җанымны
Кайларга алыплар барасы?!
Яфраклар түшәлгән юлларга
Капланмый ничекләр каласы?!

Яфраклар түшәлгән юлларга
Тоташкан гомерем юллары.
Ак җаным! Мин сине саргайтмый
Яшәргә тырыштым - булмады.

Җирдән тоеп җан җылыңны,
Шуннан хәлләр ала идем.

Дөнья гамен читкә куеп,
Сагынып сиңа бара идем.
Бер кемең дә юк бит, диеп,
Күз яшьләрең тама иде,
Өзгәләнеп кала идең.

Кочакка алып җанымны,
Шәфкатьләрең яба идең;
Ач йөрмә, дип, ак күмәчне
Бишторемә сала идең.

Ходаеңа баккан җаның
Әулиядәй балкый микән?..
Ятимнәрне, сабыйларны
Афәтләрдән саклый микән?!

## Хыялдагы бәхет

Яшьлегемә кайтып шушы юлдан,
Мин бәхетләр эзләп киткәндә,
Елап калды безнең күрше эте,
Елап калды, басып читәнгә.

Уйлагандыр инде әрни-әрни;
И син, тиле, кая китәсең?
Унбиш яшь тә юк бит үзеңә, дип,
Бар иде бит әле үсәсең...

Белгән мәллә үзе, сизгән мәллә,
Чын бәхетләр җирдә юклыгын?
Ә мин хыялланып уйлаганмын,
Аңламыйча язмыш шуклыгын.

Ишетмәгән кебек теге чакта
Елап калган этне читәндә,
Беркем тыңламады мине ул чак,
Җил улады бары чигәмдә. ..

## Моңсулык

Нигә шулай йөзең моңсу, диеп
Сорый миннән күргән танышлар;
Бәлки, шулай моңсу итәдер, дим,
Галәмнәрдән иңгән сагышлар.

## Әманәт

Хак исемен телдән төшермәдем,
Җир читенә тәкъдир илтсә дә.
Хаталарым булса, кичерә күр,
И Ходаем, берүк читләмә!

Кыйбланда булды өметләрем,
Авырлыклар чиксез килсә дә.
Язмыш диңгезенә китеп барам,
Әманәтең салып иңсәмә.

* * *

*Рәссам дустым Наил*
*Лотфуллин истәлегенә*

Ачылды да капка, ябылды,
Җил елады ызбам каршында.
Әллә нинди уйлар башымда,
Тукта, йөрәк, тукта, ашкынма!

Әллә берәр хәбәр китергән
Ерак калган туган илемнән.
Исте җилләр ярсып Иделдән,
Гүя тулпар аңа җигелгән.

Әллә берәр хәвеф-хәтәрме,
Чын дөресен җилләр әйтерме?
Кояш яшьле күзен яшерде,
Салкын яңгыр юды яшемне...

## Гаҗәпләну

Үзгәрүчән бу дөньяда яшим үзем,
Аңлый алмыйм һич кенә дә дөнья серен;
Гаҗәпләнеп өнсез калам һәр мизгелгә,
Шуңарданмы нурлана күк күңел күзем.

## Әверелеш

Салкын уйлар эреп, бәгырь савытлары
Тулар сымак ярсу хисләр белән.
Әвереләм мең төрлегә шулай,
Мең үләм дә гүя мең терелэм.

## Кем уйлаган?

Мин еракта, юлда идем ул чак,
Тормыш даласында ялгыз илче.
Яшәү миңа шундый кызык иде,
Күк каты да ул чак җиде иде.

Җырлый иде көннәр һәм өметләр,
Киләчәкләр ак таңнарда иде.
Яшьлек дәрте дулкын-дулкын кайный,
Хисләр иле тантанада иде.

Җиде тараф җиде әкият иде,
Бөтен галәм көзге төсле иде.
Әкият кызы көтә иде гүя,
Кураенда уйнап серле көйне.

Барган юлым туры кебек иде.
Көтмәгәндә давыл, туфан кубып,
Юлларыма тау-тау кайгы өйде.
Кем уйлаган ул чак афәт җиле
Өзәр диеп безнең матур көйне...

## Яралды моң...

Сахралардан исте җилләр,
Ә мин очалмадым;
Күк катыннан килде бәхет,
Ә мин тоталмадым;
Яратканым бер кыз булды,
Ә мин кочалмадым;
Күңелемдә яралды моң,
Тыңлап туялмадым.

## Таркау уйлар

Уйларымның тәрәзәсе капыл
Ачылып китте һич тә аңламастан.
Яфраклар түшәлгән юлларга
Капланмый ничекләр чыдаем!
Инәлгән җанымны тыңлар да
Ярлыкар Ходаем.

## Балачак чакырды

Еллар үткән саен, эндәшә күк
Ераклардан миңа балачагым.
Оныта күрмә, диеп әйтә кебек,
Миңа берчак әле кайтачагың.

Син онытсаң, төшләреңдә тагын
Хәтер булып килер үксез чагың;
Офыклардан аваз сала-сала,
Шул мизгелгә тагын кайтачагың;
Искә төшеп үткән гомерләрнең
Алларыңа килеп басачагын;
Чыңлап торган газиз чакларыңа
Сине әле алып кайтачагын.

Нигә икән төшләремә кереп
Үксеп-үксеп чакыра балачагым?

## Тынычлану

Ташлап китәм сезнең илегезне,
Калдырамын җирегезне, үзегезне.
Кайтып китәм үксез балачакка,
Саф чишмәләр аккан туган якка.
Матуррак иде тормыш ул вакытта,
Яхшы иде агайлар да, апайлар да.

Китәм инде үз илемә - Күккә,
Үксезлегем бетәр, бетәр күңелемдә үпкә.

## Көн баешы

Ачы җилләр чал чәчемне тарый,
Борылып багам үткән елларга.
Хәтер тузанында югалтканны
Табалмыйча йөрим юллардан.

Тормыш баскан авыр иңнәремдә
Өннәр туе кебек җил йөри.
Уйлар тынгы бирми иртә-кичен,
Киләчәкләр тагын ни юрый?

Җанны кискән вакыт җилләреме
Теләкләрне күптән җимергән.
Өметләрем, эшкә ашмаенча,
Яфрак булып юлга сибелгән.

Офыкларда әнә көн баешы,
Соңгы кошның соңгы тавышы.
Офыкларга сеңә бара гүя
Мин яшәгән еллар сагышы.

**РЕДАКЦИЯДӘН.** **Танылган рәссам һәм шагыйрь Хәмит Латыйфка күптән түгел 60 яшь тулды. Шушы уңайдан гәзитебез дустын күркәм юбилее белән ихластан котлыйбыз, аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары һәм ныклы сәламәтлек телибез.**